Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Ямаш авыл Советы

КАРАРЫ

25 февраль 2022 ел № 40

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Ямаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 елешe, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Ямаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл Советының 2015 елның 27 февралендәге 137 номерлы карары белән расланган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру (кабул итү) турында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Ямаш авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан килешүләр төзү тәртибе нигезендә

Ямаш авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1.«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Ямаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты вәкаләтләрен тапшырырга:

-җирлекнең муниципаль милкендәге мелкәт белән эш итү;

- җирлекнең муниципаль мелкәте реестрын алып бару.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советына карауга җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Кәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетында җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга тапшырыла торган бюджетара трансфертларны билгеләргә тәкъдим итәргә.

4. «Ямаш авыл җирлеге вәкаләтләренең бер елешен Әлмәт муниципаль районына тапшыру турында» 2020 елның 12 маендагы 106 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Кәләй авыл Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Ямаш авылы, Совет урамы, 109а йорт; Зәй-Чишмә

авылы, Югары урамы 186 йорт; Березовка авылы, Горная урамы, 46 йорт, Нолинка авылы, Урман урамы, 3 йорт; Петровка поселогы, Үзәк урамы, 10 йортторак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз кеченә керә һәм үзенең гамален 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ямаш авыл җирлеге башлыгына йекләргә.

Ямаш авыл җирлеге
башлыгы — Е.С.Ларин